БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«_10_» ___02___ 2020 ел. № _88_

**«Балтач муниципаль районы территориясендә муниципаль торак фондыннан файдалануга һәм аны саклауга, әлеге фондның торак урыннарының билгеләнгән санитария һәм техник кагыйдәләргә һәм нормаларга, законнарның башка таләпләренә туры килүенә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру турында» административ регламентны раслау хакында» Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2019 елның 24 маендагы 211 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Торак кодексының 20 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон, «Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында» 2011 елның 10 октябрендәге 72-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча муниципаль вазыйфаларны үтәүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 23 апрелендәге 275 номерлы карары, Балтач муниципаль районы Уставы, Балтач муниципаль районы башкарма комитеты карар бирә:

1. «Балтач муниципаль районы территориясендә муниципаль торак фондыннан файдалануга һәм аны саклауга, әлеге фондның торак урыннарының билгеләнгән санитария һәм техник кагыйдәләргә һәм нормаларга, законнарның башка таләпләренә туры килүенә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру турында» административ регламентны раслау хакында» Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2019 елның 24 маендагы 211 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 2 бүлекнең 2.4.1 пунктындагы 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) дәүләт торак күзәтчелеге органына тапшырылган әлеге эшчәнлекне гамәлгә ашыра башлау турында хәбәрнамә нигезендә торак милекчеләре ширкәте, торак, торак-төзелеш кооперативы яисә күпфатирлы йортлар белән идарә итү

эшчәнлеге буенча башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативы тарафыннан гамәлгә ашырыла башлады. 294-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Планда түбәндәге белешмәләр булырга тиеш:»;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм ТКХ бүлеге башлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач район
башкарама комитет
җитәкчесе А. Ф. Хәйретдинов